**ГЛАВА ШУМБУТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422664, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, с. Шумбут,
ул. Советская, дом 18

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ШОМБЫТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422664,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы,
Совет урамы, 18 йорт

Тел.: (84361) 33-100, факс: (84361) 33-100, эл.адрес: Smb.Rs @tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2024 с. Шумбут № 4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шестая Речка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Шомбыт авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шестая Речка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.
2. Халык җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге составына керүче Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Красный Яр, Степановка авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре, СВОда катнашучыларының гаилә әгъзалары) 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау һәм кышкы карап тоту;
- «БЕЛАРУС 82.1» тракторын карап тоту, тракторист эшләре өчен килешү буенча түләү, ГСМ чыгымнарын түләү өчен;
- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын карап тоту (су челтәрләрен ремонтлау, тирән насослар сатып алу, су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү);
- Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Степановка, Кызыл Яр торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар һәм аларга комплектлау өлешләре сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә чүп үләннәрен чабу, территорияләрне җыештыру, Бөек Ватан сугышында катнашучыларнын обелискларын ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы, Шомбыт авылы, Совет урамы, 18нче йорт, Шомбыт авылы, Завод ур., 22ж йорт, Шестая Речка авылы, Урман урамы, 6 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга..

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Шомбыт авыл җирлеге башлыгы Н.Е.Сергеев